**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару эшен оештыру турында

Икътисад үсешенә этәргеч бирү һәм Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне заманча идарә технологияләрен кулланып базарларга чыгару өчен шартлар тудыру максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының республика маркетинг үзәген эшләтү, zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгыннан һәм Татарстан Республикасының электрон товар-мәгълүмат системасыннан (www.tattis.ru) файдаланып, товар җитештерүчеләр арасындагы кооперация бәйләнешләрен анализлау һәм исәпкә алу керә торган Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгаруга идарә итү системасын (алга таба – Система) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 60 көн эчендә Системаны төзүне, анда катнашучыларның үзара хезмәттәшлек итү регламентын һәм алар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен билгеләүне күздә тотучы норматив хокукый актлар эшләргә һәм чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Системаны төзүдә һәм эшләтүдә катнашуны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 05 март
№ ПУ-157